РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 май 2025 ел № 18

Түбән Кама шәһәр Советының 2024 елның 28 мартындагы 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәренең җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше Кодексының 31, 32 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 14 статьясындагы беренче өлешенең 20 пункты нигезендә, 2025 елның 27 мартында үткәрелгән гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәр Советының 2024 елның 28 мартындагы 10 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә кертелә торган үзгәрешләрне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Уставында билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше сәясәте һәм архитектура идарәсенә Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында расланган документны урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры вазифаларын башкаручы, Мэр урынбасары

М.В. Камелина